


Чаян

ISSN 0134-384

САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ * МАЙ * 2016 * КАЗАН

10



Эрнест ДЫШАЕВ

АННАН-МОННАН ИНФОРМ

СОҢГЫ ХӘБӘРЛӘР

● Конституцион суд эшләмәгән, әмма эшли алырдай гражданнарга салым салуны хөкүмәткә каршы чара дип кабул иткән.

● Украина, Евровидение-2017 не Кырымда уткәру исәбе белән Сергей Лазаревның җиңүен таныды.

● Халыкара Олимпия комитеты олимпия лозунгын яңартты — “Иң мөһиме — җиңү түгел, ә анализларны тапшыруда катнашу”.

● Немецлар күкрәк кагып әйтә: иң күренекле Рәсәй дирижеры — исерек Ельцин.

● Үзәк Разведка Идарәсе (ЦРУ) докладында әйтелә: Рәсәй чит ил агентларының күплеге буенча иң алдынгы дәүләт.

● Европада берҗенеслеләрнең аерылышуларына каршы чыгышлар киңәя.

● Пенсия фонды күкеләрне атарга тендер игълан итте.

● “Йөзграммнансоң” социаль челтәре эш башлады.

● Санкт-Петербург халкы күктә яп-якты шар барлыкка килүеннән курка калды. Галимнәр, шәһәрдә яшәүчеләргә әлеге объектның Кояш икәнлеген аңлатып, аның бернинди дә куркыныч тудырмаячагын төшендерделәр.

● Сәрхушләргә аерым банкомат ясалган. Аңа теләсә нинди пин-код ярый икән.

● Физиологлар, күз алдыннан бөтен гомерең үткәнче реклама роликлары булып алачагын ачыклаганнар.

● “Шырдый“ агентлыгының социаль сораштыруы һәр ике ирнең берсе үзенең гел беренче булуы турында уйлавын ачыклаган.

● Мэрия паркоматлардан килгән керемнең кимүенә борчыла. Чөнки машиналар тыгылгач, бөкеләр түләүсез паркингларга әверелә.

● Эшкә урнаштыру бюросыннан куылган хезмәткәр икенче көнне үк яңадан шунда эшкә килгән.

● Бу җәйне модада ертык джинсылар үтүктән калган тап белән булачак.



Виктор ФЁДОРОВ

ШОМБАЙ болай диде...



Хөрмәтле Чаян! Рәсми статистика мәгълүматлары буенча, республикада уртача хезмәт хакы 30 мең сумнан арткан икән. Бу турыда белгәч, күрше-күләнне, дуслар һәм туганнарны сораштырып, үзем кечкенә статистик тикшеренү ясарга булдым. Кызганыч, алар арасында беркемнең дә мондый акча алмаганы ачыкланды...

Л. ХӘСӘНОВА


КУКМАРА

– Статистика ул – бик сәер нәрсә, – диде Шомбай ага, укучыбызның хатын укып чыккач. **– Менә күптән түгел генә профессионаллар Австралия өчен тавыш бирде, тамашачылар – Россия өчен, ә Украина җиңүче булды ...**



Илдус АЗИМОВ

Вячеслав БИБИШЕВ



Антон МАКУНИ

ЯЗ КИЛДЕ

Яз килде. Назлы яз кояшы җиргә җылы нурларын сипте. Карчык-корчыклар тәкәббер кыяфәт белән подъезд янындагы эскәмияләргә чыгып кунаклады.

Быелгы бензин һәм запчасть бәяләре турында гәпләшеп, гараж яннарында автомобиль хуҗалары чөкердәшә.

Саф җилдән яшелләнеп, доллар кыштырдый; үзенең күз камаштырырлык төсләре белән, җанны шатландырып, евро өскә үрелә. Алар артыннан, дәртләнеп, төрле бәяләр, тарифлар, акцизлар, салымнар күккә омтыла.

Ягымлы итеп сайлауларга әзерләнүче кандидатларның чираттагы вәгъдә инешләре челтери.

Салымнарын түләргә өлгергәннәрнең намусы кебек, һава саф һәм чиста.

Аю-олигархлар, салмак кына коттедж-өннәреннән чыгып, чираттагы дәүләт милкен бүлешү умарталыгына җыена.

Кышкы йокыдан соң бакчачы-кырмыскалар якты дөньяга чыкты. Үзләренең иске «Жигули»ларында сикәлтәле җимерек юллардан алар үсентеләр һәм төзелеш материаллары ташый. Шунда ук, җир астыннан калкып чыккан шикелле, тырыш кондыз-гаишниклар пәйда була! Алар, юл агымын буып, язгы дәрт белән үткен тешләрен кышкы чыгымнардан соң югарып калган гаилә бюджетына батыра.

Инде беренче язгы яшен, компромат һәм фаш итү күкрәүләре дә ерак түгел. Ә аннан соң инде чиратта җәйге янгыннар һәм сәяси «бүләкләр»...

Яз килде!



Илдар НӘФИЕВ



Интернет безнең тормышыбызга котырынып, тотрыклы гореф-гадәтләрне һәм ияләнелгән яшәү тәртибен җимереп, үзенең яңа кануннарын урнаштырып килеп керде. Кайберәүләрнең күңелендә аңа каршы торырлык көч яши әле, ә икенчеләр исә ул татлы диңгездән башка яшәүне күз алдына да китерә алмый. Соңгыларының саны миллионнар белән исәпләнә һәм аларның байтак өлеше – балалар. Төрле мәгълүматлар буенча, бөтендөнья челтәрендә яшь файдаланучыларның өчтән бере «буталып калган». Алар чынбарлык белән араларын тулысынча өзеп, виртуаль дөньяда яши.

Интернет белән бәйле «ычкыну» мисаллары ил буенча буа буарлык. Дөньядан ваз кичеп «канлы» уеннар уйнап утыручылар, «челтәр»гә керү мөмкинлегеннән мәхрүм ителү аркасында үз-үзләренә кул салу турындагы җан өшеткеч вакыйгалар шаккаттыра.

Безнең «айти-технологияләр» өлкәсендә алга киткән республикабыз да бу шаукымнан читтә калмады, билгеле. Берничә ел элек кунакка килгән малайның әбисенең өендә Интернет булмаган өчен аның башына чүкеч белән сугу очрагын барыбыз да хәтерлидер. Шулай ук Карамалы Тау бистәсендә электрны ялгыш өзеп, аны «челтәр»дән аерган әтисенә ташланган 17 яшьлек яшүсмер дә истә. Күптән түгел Лаешта 10 яшьлек малай бернинди җитди сәбәпсез үзенең гомерен кискән. Тикшерүчеләр бу вакыйганы Интернет белән бәйле дип саный. Чаллыда иҗтимагый челтәрдә телгә килгәннән соң, классташына пычак белән кадаган. Казанда яшүсмерләр төркеме иҗтимагый челтәрдә яшьтәшләрен җәберләү һәм куркыту белән шөгыльләнгән.

Балалар арасындагы җинаятьләрнең һәм искә алынган күңелсез очракларның яртысы «челтәр» белән бәйле булуга карамастан, өлкәннәр, чигеннән ташып чыккан бу проблеманы хәл итәргә ашыкмыйлар. Кул кушырып утырмыйлар, әлбәттә. Мәсәлән, башкала хакимияте балалар бакчаларының өлкән группаларында Интернет турында махсус профилактик дәресләр кертү турында тәкъдим кертте. Тик беркатлы депутат абыйлар өлкән группаның моның өчен соң икәнен аңламыйлар, күрәсең. Бу «авыру» күпкә иртәрәк, чүлмәк өстендә пес итеп утырган чакта ук сизелә башлый.


Республика парламенты депутатлары да бу мәсьәләне чишүгә үз өлешләрен кертергә булдылар һәм онлайн-казинода катнашучыларны җәзага тартырга дигән тәкъдим белән чыктылар. Балигъ булмаганнарны бу уеннарга тарткан өчен ун мең сумга кадәр штраф каралган. Ел башында Россиянең кайбер мәктәпләрендә куркынычсыз селфи дәресләре уздырылды. Инде бу юнәлешнең методикасы өстендә эш башланган, диләр. Балалар «чире» өлкәннәрнең фәнни эшчәнлеге өчен зур киңлекләр ачты. Диссертацияләр, тикшеренү оешмалары Интернет корбаннары санына караганда тизрәк үрчи.

Кытайда бу мәсьәләне кискенрәк хәл итәләр. Илдә «челтәр капкынына» эләккән балигъ булмаган гражданнарны кабул итүче ике йөзләп махсус клиника эшли. Спорт, физик хезмәт, кешечә аралашу (гаджетлардан башка, әлбәттә!) – мондагы төп тәрбия ысулы. Чиктән ашкан «юзер»ларга карата, оялып тормыйча, электрошок файдаланалар. Дәвалану түләүле. Ата-аналар арасында баланы «кисәтү» ысулы белән тәрбияләү бик популяр. Ул бала әле компьютер өстәленең астында йөргән чакта ук кулланыла башлый. Аның асылы – шартлы рефлексны «өзү». Компьютерны ялгаган чакта нарасыең-ның – кулына, ә тыңлаусызрагының башына чәпеп алырга кирәк. Тик моның бер хикмәте бар – баланы «гасыр могҗизасы» ялганганнан соң чәпәләү файдасыз: бу очракта ысул нәтиҗә бирмәячәк.

Бу темага күп шаяртырга була, әлбәттә. Ләкин проблема шундый дәрәҗәгә җиткән ки, чәпүләр инде ярдәм итмәячәк: җавапка баш түбәнә чүкеч белән алуың бик мөмкин. Әгәр компьютердан мәхрүм булу бала өчен иң куркыныч җәза булып кала икән, мәктәп укучысы, «бу турыда Интернетта укырга була», дигән өй эшләре алып кайта икән, «компьютер чире» һаман киңрәк һәм тирәнрәк тамыр җәячәк.

Людмила САФИУЛЛИНА

Вячеслав ШИЛОВ



Константин МАЛЬЦЕВ



Максим СМАГИН



Виктор ФЁДОРОВ





• • •

Табиб авыруның анализларын өйрәнә, тегесе:

— Доктор, минем эшләр ничек соң анда?

— Һм, кредит алырга мөмкинлегегез бар.

— Минем аны түләргә хәлемнән килми.

— Сезнең андый җай булмаячак та.

• • •

— Сәлам, чибәркәй! Синең егетең бармы?

— Ә син нинди максат белән кызыксынасың? Мине иремнән аермакчы буласыңмы?

• • •

Безне биләүдә чактан ук шундый фикергә китерәләр: үзеңнең хокукларың турында нихәтле кычкырсаң да, барыбер авызыңны нинди дә булса буш суыргыч белән томалыйлар!

• • •

— Сәлам, хәлләрең ничек?

— Менә отпускка китәргә исәп.

— Хатының беләнме, әллә ялгамы?

• • •

Математика профессоры ЖКХдан счет-фактура алгач, аны үзенең аспирантларына биргән. Яшь специалистлар, моны алганнан соң, әлеге линиядә булмаган тигезләмәләр системасының дөрес саннар өлкәсендә чишелеше юк икәнлеген ачыклаганнар.

• • •

Киштә кую өчен күршегә мөрәҗәгать итәргә була... Ә менә талаша-талаша, ызгышып, кыек итеп куяр өчен — моңа инде ирең булуы кирәк!

• • •

Фронтовик:

— Хәтеремдә, кайчандыр Евросоюз белән безнең визасыз элемтә бар иде. Шуңа күрә миңа Прагада, Варшавада, Будапештта, Венада, Берлинда булырга мөмкинчелек туды.

• • •

Мавроди күккә ашкан. Алла, аны очратып, сораша башлаган:

— Җирдә синең гөнаһларың булдымы?


— М-м-м, — дип мыгырданган Мавроди.

— Афәрин, ялганлап маташмыйсың.

• • •

— Татар малае әтисеннән сорый: “Русча иншада “Зимой в магазине продается много пальто или польт” дип язуның кайсысы дөрес?”

— Җәй турында язып котыл син моннан, улым! — дигән әтисе.



Бер уйласаң, юмор һәм хокук саклау системасы — икесе ике төрле, бер-берсе белән чагышмый торган төшенчәләр, ләкин бу бер карашка гына шулай. Кызык һәм көләрдәй хәлләр җитди оешма хезмәткәрләре катнашында да барлыкка килергә мөмкин. Безнең автор, Татарстан Республикасы прокурорының ярдәмчесе, юридик фәннәр докторы Флер Баһаветдинов үзенең рус телендә чыккан "Закондагы юмор" китабында шул кызык хәлләр турында мавыктыргыч итеп яза.

ТАРАКАНЛЫ ШИКАЯТЬЛӘР

Төрле шикаятьләр була. Гадиләре һәм гадәти булмаганнары, гадиләре һәм гаҗәеп үзенә бертөрлеләре. Соңгыларының берсенә, һичшиксез, Түбән Новгород өлкәсендә үзенең җәза вакытын үткәрүче хөкемгә тартылган О. туры килә. Ул Татарстан Республикасы прокуратурасына даими рәвештә үзенең җинаять эшенә кагылган мәсьәләгә шикаятьләр җибәрә. (Аны хөкем итү Татарстан Республикасында үтә.) Аның бер "фишка"сы бар — шикаятенә ул үлгән таракан беркетә. Бу гамәле белән ул нәрсә әйтергә теләгәнен берәү дә ачыклый алмый.

Бервакыт без аның чираттагы шикаятен тикшереп, моның сәбәбенең асылына төшенергә маташтык. Бәлки, аның башына тараканнар оялагандыр? Бәлки, анда тараканнарга карата рәхимсез чаралар кулланадыр? Республика прокурорының ярдәмчесе Р. Хисаметдинов бу мәсьәләгә ачыклык кертте: "Ул үзенең барлык шикаятьләренә үлгән тараканнар беркетә. Ә тараканнарның хокукларын бозуга килгәндә, алар безнең тараканнар түгел, Түбән Новгородныкылар, шуңа күрә аларны үз өлкә прокурорлары якларга тиеш".




КЕСӘЛНЕҢ ФАЙДАСЫ ТУРЫНДА ӘҢГӘМӘ

2012 елда полициягә Казанда яшәүче берәүдән гариза керә. Яшь ханым үзенең 5 яшьлек улыннан зарлана. Бу фактны тикшерү өчен балигъ булмаган балалар белән эш итүче хезмәткәрне җибәрәләр. Тәртип саклаучы шундук икенче бүлмәдә елаучы бала тавышына игътибар итә. Әнисе баланы тынычландырырга кереп китә. Аның артыннан бүлмәдә пәйда булган хезмәткәрне күрүгә, әлеге бакыр чәчле малай елаудан шып туктый. "Монда эшләр болай, — дип каушабрак башлый сүзен малайның әнисе, — безнең улыбыз кесәл эчми. Аның ашказаны белән проблема, шуңа күрә табиблар дару урынына шушы эчемлекне тәкъдим итте". Полиция хезмәткәре гомерендә әллә ниләр күргәне һәм ишеткәне бар, әмма полиция ярдәме белән балага кесәл эчертергә мәҗбүр итүне башкарганы булмаганын әйтә. Шулай да, аптырап калмый, бакырбашка кесәлнең файдасы турында гына түгел, шуңа өстәп тәмәкенең, аракының, наркотикларның да зыяны хакында лекция сөйләп бирә. Бала шулхәтле игътибар белән тыңлый ки, соңыннан аңа әле өстәмә сораулар да биргәли. Лекциясен яхшылап укып тәмамлагач, үз эшеннән канәгатьлек хисләре белән тәртип саклаучы саубуллашып чыгып китә.

Озакламый тәртипсез малайның әнисеннән рәхмәт хаты килеп төшә. Хезмәткәребезнең тирән эчтәлекле әңгәмәсеннән соң, улым рәхәтләнеп кесәлен эчә, диелә анда. Күрәсең, малай кесәлнең файдасын күрә башлаган.





• • •

Зоопарка экскурсия:

– Уң якта сез – ата гориллаunion, сулда ана гориллаunion күрәсез.


– Аңлашыла. Ә горилла үзе кайда соң?

• • •

Бер атна ач торганнан соң, арыслан, ниһаять, зоопарк каравылчысын хайваннар патшасы дип таныды.









ШИГЪРИ ДУЭЛЬ

Рашат Низами:
Диңгез исе килгән чәчләреңне
Ак мендәргә салдың таратып...

Алмаз Хәмзин:
Назларыңнан азып кызган чакта
Килә иде инде таң атып.

Р. Н.:
Хәбәрең юк, яшәп ятыш әле
Урмандагы ялгыз йорт сыман.

А. Х.:
Рәхәтлеген әйтеп тормыйм, яме,
Килеп йөрмә, — сөю басылган.

Р. Н.:
Күзләреңдә кояш байый —
Ни булды икән сиңа?

А. Х.:
Сорап торма, махмырдан ул —
Давай, син мине сыйла!

Р. Н.:
Шакып-шакып карыйм да күкләрне,
Җавап эзлим сорауларыма...

А. Х.:
Андый хәлгә җиткәч син, дускаем,
Психбольницага барып кара.

Р. Н.:
Заманага ачы сүгенеп, мин
Кара төнне, ахры, куркыттым.

А. Х.:
Һәм, ниһаять, кара көннәр килде...
Кабат сүген, Рашат, кайтарт төн!

Олег **ПРЯНИЧНИКОВ**

ҖАН ҖЫЛЫСЫ

Чиновниклар янына йөрергә яратам мин. Чын мәгънәсендә яхшы күңелле, самими кешеләр алар. Аларга карап тору гына нәрсә тора. Менә мин аңа текәлеп карап торам, ә ул миңа. Карашы белән җан җылысы сирпеп, сорый:

— Сезгә нәрсә?

— Миңа процентсыз кредит алырга иде, бизнес өчен.

— Сез фермермы?

— Юк, — дим, – мин бакчачы. Бакчада баклажан үстерәм. Ә чынлап — минем юмор журналы ачасым килә. Кешеләрнең күңелен күтәрергә.

Шунда аның күз карашы җылынып китә.

— Беләсезме, — ди ул серле тавыш белән, — без сыерлык акча бирә алабыз. Хәтта бирергә телибез. Хәзер безнең программа – сыер алырга дигән акчаларны тиз арада таратып чыгу. Сез үз йортыгызда торасызмы?

— Бер бүлмәле фатирда, — дим. — Тик анда бер сыер яши инде – теща. Өстәвенә, хатын, биш яшьлек бала.

— Шулкадәр халык бер бүлмәдәме?— дип җанлана ул. — Алыгыз, зинһар өчен, сыерлык акча. Тик соңыннан сыер алуыгыз турында белешмә китерергә онытмагыз. Сезнең балконыгыз бармы?

— Бар.

— Бик шәп! Сездә бит сыер тотар өчен бөтен шартлар бар!

— Ә астагы күрше ни дияр? Сыер бит ул... теге...

— Ә сез җәймә, клеенка җәегез. Балагыздан калгандыр бит?

— Ә! Искә төште! Ә баланы бакчага урнаштырсак ничек? Ярдәм итәрсезме? Аңа инде тиздән мәктәпкә барасы, ә бакчага йөреп караганы юк, һаман чират җитми.

— Ю-у-ук, бакча белән катлаулырак. Һәм сезнең өчен кыйммәтрәк булыр. Күтәрә алмассыз... – ди чиновник.


— Алайса хатынымны эшкә урнаштырыгыз, ә? Яхшы урынга. Бала белән сыерны теща карар иде...

— Ю-у-ук, яхшы урыннар күптән алынып беткән инде.

— Тә-ә-к, — дип уфтанам мин. — Сезгә сыерлык акчаларны кешеләргә тарату кыенрак булыр.

Китәргә дип торам, ә ул һаман өмет белән күземә карый.

Чиновниклар янына йөрергә яратам мин, әйбәт кешеләр алар... Тик менә сыер белән нишләргә белмим, балконда төннәр буе мөгрәп чыга...



Виктор **БОГОРАД**

Вячеслав ШИЛОВ



Сергей ЕРМИЛОВ





“ЯРЛЫ” БАШЛЫК

Менделеевск шәһәрендә гадәттән тыш хәл булган. Җирле Башкарма комитетының Яшьләр һәм спорт идарәсе башлыгы... үзенең хезмәт хакын киметкән. Тик нишләптер бу игелекле гамәл хокук саклау органнарында аңлау тапмаган. Анда моның файда табу максаты белән эшләнгәнне ачыклаганнар. Башлык үзенең хезмәт хакын бары тик кәгазьдә генә, торак-коммуналь түләүләргә субсидия алу өчен “кискән”. Дәүләтне 49 мең сумга ярлыландырган чиновникка хәзер 130 мең сум штраф түләргә туры киләчәк.

ӨЙЛӘНЕШҮ КОНВЕЙЕРЫ

Владивостокта ЗАГСның район бүлеге мөдирен хөкем иткәннәр. Шома ханым безгә килгән Үзбәкстан гражданнары һәм россияле хатыннар арасында ялган “өйләнешү конвейеры” оештырган. Әйтергә кирәк, “яшь кәләшләр” гаилә хәлләре үзгәрү турында белмәгәннәр дә — “никахлашу” алардан башка эшләнгән. Һәр “яшь кияү”дән мөдир ханым бишәр мең сум алган — россияле хатыннарның ирләре булып киткәч, алар бернинди катлаулыкларсыз эшкә урнаша алганнар. Хәзер инде “бәхетле гаилә”ләрне аеру белән суд шөгыльләнәчәк.

ГОРУРЛЫК ӨЧЕН СӘБӘП

21 елга хөкем ителгән террорчы Андерс Брейвик Норвегия хакимиятен судка биргән һәм эшне отып чыккан. Ул үзен төрмәдә тоту шартларының кешелексез икәнлеген исбатлый алган: өч бүлмәле камера кысан, иртәнге кофе салкын, ә электрон уен җайланмасы иске. Йөз кеше үтергән җинаятьчене бигрәк тә табынучыларын янына кертмәүләре газаплаган. Хакимият гаебен таныган — аның утыру шартлары яхшыртылачак. Суд нәтиҗәләре буенча, Норвегиянең Премьер-министры, бу очрак Европа демократиясе белән горурланырга тагын бер сәбәп, дип белдергән.

Рәис ГАЙНЕТДИНОВ

ВИТАМИННАР КАПЧЫГЫ

Әй мактап та куялар соң шул кабак дигәннәрен: витаминнар капчыгы, бакча короле, ә урыслар хәтта “барыня”, ягъни байбикә дип тә атыйлар икән әле аны. Кеше организмы өчен аның файдасын әйтеп бетерерлек кенә түгел, диләр.

Шуны белә торып та, үзебезнең алты сутый бакчабызда моңарчы ничек урын табылмаган соң “корольгә”! Ә менә быел бер түгел, биш төп утырттым.

Менә уңыш җыяр вакыт та килеп җитте. Әстәгъфирулла, кабакларны бер күчкә җыйгач, Ташкент урамнарындагы карбыз өеменнән бер дә ким булмады. Горурлыгым эчемә сыймаганга, хезмәттәшләргә, дус-ишләргә, күршеләргә сөйләп, аларны туйдырып бетердем.

Тора-бара, мактануларымнан туктап, кабак белән ни кыларга кирәклеге хакында баш ватарга керештем. Бакчада калдырып булмаганга, иң беренче эш итеп, балконыбызга кайтарып тутырдык. Хатын белән киңәшеп, көн саен ашау рационыбызга витамин кертергә булдык: кабак бәлеше, бәрәңге белән томалап пешергән, духовкада кыздырылганы, кабак кыстыбые, кабак согы, төшләрен кыздырып чемчекләү дисеңме, берсен дә калдырмадык.

Көн дә, көн дә кабатлана торгач, берничә атнадан кабакка борылып та карыйсыбыз килми башлады. Ә аларның саны һич тә кимергә уйламый гына бит. Базарда сатып утырырга вакытыбыз да, теләгебез дә юк, ә шундый файдалы җимешне хөкүмәтебез дә кабул итми икән; күршеләр, туган-тумачалар да кирәге кадәрен алгач, тәкъдимемне кире кага башладылар. Аптырагач, “Бушлай кабак алыгыз!” дип подъезд ишегенә белдерү дә ябыштырып карадым. Әллә аны шаярту гына дип кабул иттеләр, бер-ике кешедән башка кабак сорап килүче булмады.

Беркөн шулай уйланып утырганда, күптән баҗай белән балдызны кунакка чакырганыбыз булмаганы искә төште. Аларны туйганчы кабак ашлары белән сыйлап, бүләккә ике-өч кабаксыз да җибәрмәячәгемә инанып, шалтыраттым үзләренә. Фәлән көнне, фәлән сәгатьтә очрашырга килештек.

Сөйләшкән вакытта шакуга шатланып, ишекне ачып җибәрсәм, Илаһым, егылып китә яздым — баҗай үзенең корсагыннан да зуррак кабак, ә балдызкаем бер метр озынлыктагы ташкабак күтәреп, елмаешып торалар...



ЙОЛДЫЗ

ДИНАСТИЯ

Элек бездә бар иде
Хезмәт династиясе:
Атасы да улы да –
Тырыш хезмәт иясе.
Болар каршында
килә гел
Горур башны иясе.
Белгәннәр хезмәт тәмен –
Тапканнар тормыш ямен.

Ә бүген безнең илдә
Түрә династиясе.
Атасы да улы да –
Кун кәнәфи иясе.
Күрмәс өчен,
эшләпәне
Килә батырып киясе. –
Бүтәннәрдә юк гаме.
Исерткән акча тәме.



Виктор ФЁДОРОВ

Михаил НИКИТИН

СҮЗ ИЯРӘ СҮЗ

Авыру үзе килә. Ә менә инвалидность алу өчен йөгерергә кирәк.

Кайчагында дәгъвачыны да, җавапчыны да, судьяны да утыртырга кирәк.

Ялгызлык түзә алмаслык нәрсә — бигрәк тә гаиләдә.

Россия – Евразия иле: бездә бәяләр – Европадагыча, ә хезмәт хакы — Азиядәгечә.

Талантны җиргә күмү мәҗбүри түгел — аны аракыда да батырырга була.

Хәнәфи БӘДИГЫЙ

ТУБЫК ЯЛТЫРАТУ

— Хәзер инде модаларга
Иярмәм! — дигән идем.
— Киемне яшьләрчә итеп,
Кияалмам! — дигән идем...

...Джинсы балагын кайтарып,
Тубыгын ялтыратып,
Бер кыз атлый, мин сиңа әйтим,
Башымны аптыратып!..

Өсте-башы — энә-җептән,
Аягында — сандали!
— Салкынча җилгә тубыгын
Ник ачкан? — дим, җәлләми?..

...Аякларыма карасам!..
Тубыкларым ачылган!..
...Ботинкалар оекбашны
Үкчәләргә шудырган!..

Кыз тубыгын мода ачкан,
Ә минеке — табигый!
Димәк, хәзер син үзең дә,
Модный икән, Бәдигый!

Александр БРЮХАНОВ

ШТАТТАН ТЫШ ЯРДӘМЧЕ

Дөресен әйтим, мин хөкүмәтне эчтән генә тәнкыйтьлим. Чөнки алар болай да бөтенесен беләләр һәм безнең шикелле үк кулларыннан килгән бөтен нәрсәне дә эшлиләр дип саныйм...

Бөтен нәрсәдә дә үзебез гаепле дип саныйм, шуңа күрә беркемгә дә дәгъва белдермичә, төннәрен үз гаебемне тоеп, газапланып ятам.

Беркемнән дә бернәрсә дә сорамыйм, чөнки бу файдасыз. Сорамыйм да, үтенмим дә, үкенмим дә, үксемим дә.

Бар көчемә кулыма кергән акчага яшәргә тырышам, чөнки аларны яшәгән гомерем белән эшләп алдым дип саныйм.

Артык сораулар бирмим. Кайчагында бирсәм дә, фәлән җиргә ничек барырга һәм сәгать ничә дип кенә.

Зыян китерердәй һәм нәрсәне дә булса бозардай берни дә эшләмим.

Шуңа күрә берәр нинди нәчәлник ярдәмчесе таныклыгы бирүегезне үтенәм. Аны беркайчан да файдаланмаска, күкрәк кесәмдә генә, үз-үземнең зур кеше булуымны тояр өчен йөртергә сүз бирәм.



ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР

Гомер буе берни эшләмәс өчен зур сәләт кирәк.
Кешелеккә чыкты, ләкин кеше була алмады.
Хезмәт хакы арткан саен, фикерләр төпләнә.
Бәхет акчада түгел, ә аның күләмендә.
Әгәр хатын-кыз ир кешенең фикере белән килешкән икән – димәк, ул хаклы. Әгәр килешмәгән икән – димәк, ул аның ире.
Дрессировщикның озак яшәве – ерткычларның казанышы.
Кешеләр башларын кыюрак күтәрә башлады, – диде палач. – Эшләү күпкә җиңеләйде.
Тормышта үз урыныңны тапкансың икән – аның бушаганын көт.
Җүләрләрнең күләме кими, ә сыйфаты үсә.
Агачлар кешеләр кебек: берәүләре өскә, икенчеләре кояшка таба үрелә.
Вөҗдан үзенә битараф булмаганнарны гына борчый.

(Зыялылар мәҗлесендә язып алынды)











УДАР ХЕЗМӘТ

Хөрмәтле редакция! Без яшәгән йорттан ерак та түгел Төзүчеләр урамында зур төзелеш эшләре башлап җибәрделәр. Берничә 18 катлы йорт төзеләчәк икән. Әлбәттә, халыкны фатирлы итү бик әйбәт эш, бигрәк тә безнең микрорайон өчен. Ләкин ул бәхетле тыныч көннәргә ерак әле. Бүгенге көндә тынлык турында хыялланырга гына кала. Эшчеләр шулкадәр кызу темпта эшиләр ки, хәтта төнлә дә эш гөрли. Төзелештән килгән шау-шуны бернинди пластик тәрәзәләр дә коткармый. Ә беренче йортны төзеп тапшырулары киләсе елның җәендә генә икән. Берничәсенә свайлар кага гына башладылар. Шулай булгач, төзелеш децибеллларын да әле безгә бик озак тыңларга туры киләчәк. Күрәсең, берничә ел элек кабул ителгән тынычлык турындагы канун бөтен кешегә дә кагылмый.

В. ИМАМОВ

ЯШЕЛ ҮЗӘН

КРЕМЛЬ ТОЗАГЫ

Кадерле Чаян! Шәһәр хакимиятенең башкалабызга килгән туристлар өчен уңайлылыкларны тагын да яхшырту өстендә эшләгәне сизелеп тора. Соңгы вакытларда туристлар саны да күзгә күренеп артты. Гади бер җитешсезлек өчен тырышлыклары бушка китмәсә.

Шәһәребезнең күп кунаклары, үзләре дә сизмәстән, “Кремль тозагы“на эләгә башлады. “Пирамида” һәм Бауман урамы аша Спас манарасына менгәндә алар шундый хәлгә кабалар. “Зебра” – юл билгесе куелмаганлыктан, туристлар юлны теләсә кайдан кичәргә мәҗбүрләр. Менә шунда көтә дә инде аларны тозак. Юлны дөрес кичмәдең, дип, ГИБДД хезмәткәрләре штраф чәпи.

Бер караганда, юл хезмәткәрләре канунга таянып дөрес эш йөртә шикелле. Дөреслектә, мондый күңелсез хәл берни аңламаган туристларның кәефен төшерә, тирә-яктагы матурлык белән сокланудан җилләр исә... Мондый “Кунакчыл”лыктан нинди тәэсир калуын аңлау авыр түгел.

Т. ГАЙНУЛЛИН

КАЗАН



• • •

Ике сәрхуш сөйләшә.

– Карале, нәрсә ул алк...алк..алкоголеанализатор?

– Шундый хикмәтле нәрсә инде ул... син аңа өрәсең, ә ул синең ни дәрәҗәдә исерек икәнлегеңне әйтеп бирә...

– Һа-һа! Кара син аны, ә! Шундый нәрсә белән ничә ел яшим бит инде мин!





Энҗе БИКМУЛЛИНА



Татарстанда гадәти булмаган, законны бозмыйча «эшли» торган мошенникларны тотканнар. Алар азык-төлек кибетләре директорларын «төп башына утырту» белән шөгыльләнгәннәр. Акча алуның тәртибе бик гади булган. Кибеткә балигъ булмаган яшь егет керә һәм үзенә алкогольле эчемлек сатып ала. Шешәне кулына алгач, егет чек белән паспортын тотып турыдантуры директор янына керә һәм закон бозу турында белдереп, «эндәшмәү» өчен акча таләп итә. Ризалашмаган очракта тикшерү органнарына хәбәр итү белән куркыта. Кибеткә янаган бөтен мөмкин күңелсезлекләрне чагыштырып карагач, сәүдә ноктасының нәчәлниге кагыйдә бозуны рәсмиләштерүнең кыйммәткәрәк төшәчәгенә һәм мәшәкатьлерәк тә булачагына төшенеп, укымышлы рэкетир сораган сумманы түли. Балигъ булмаганнарга алкоголь сатуны тыю турындагы закон бөтен җирдә дә үтәлми, күрәсең, мошенниклар эшчәнлеге нәтиҗәсендә, берничә дистә кибет зыян күргән.



ҮТКӘННӘРГӘ КАРЫЙК КАЕРЫЛЫП

Сара апа белән очрашкан, сөйләшкән мизгелләрне искә төшереп утырам. Минем студент чак. "Бөркет турында баллада"сын җырлаганны ишеткән, күрәсең, үзенең Татарстан урамындагы яңа фатирына чакырды. "Яңа җырлар күрсәтәм сиңа", — ди. Ишегенә звонок бирүем булды, ялт итеп килеп тә чыкты — кызлар кебек маэстро! Минем буш кулларыма карады да:

— Бәрәч, торт та алып килмәдеңмени? — диде. — Чәй эчәрбез дигән идем.

Уңайсызлануым йөземә бәреп чыкканны сиздем — битемә кан йөгерде, кып-кызыл булганмындыр... Үзем дә инде ахмак... Шундый кеше янына бер күчтәнәчсез килгәнмен.

— Хәзер, Сара апа, — дидем дә кибеткә йөгердем. Тагын биш тапкыр ашханәдә ашарлык акчама зур торт алып, яңадан звонокка бастым. Дулкынланам, хәзер ни әйтер икән? Чак кына ачык калган ишек артыннан:

— Кер! — дигән тавышы ишетелде.

Тыйнак булган кебек, тортны тапшырдым.

— Әйбәт торт алгансың, зурны, Гөлшат Зәйнашева да киләм дигән иде әле бүген.

Ул үзенең зарын сөйләргә тотынды.

— Менә балкон ягындагы тәрәзәмне ваталар. Инде икенче тапкыр таш белән. Менә, менә, кара, — дип, тәрәзә тупсасына куйган йодрык хәтлесен күрсәтте.

— Нигә аталар, ник ваталар, нинди ачулары бар, кемгә начарлыгым тигән? Милициягә гариза яздым, шуны кертеп чыгарсың әле, яме?

— Ярар, Сара апа, борчылма, кертермен.

— Менә сиңа ике җыр күрсәтәм. "Мин сандугач булсам"ны һәм "Яле, яле" дигәнне. Тыңла, уйныйм.

Сара апа уйный торгач җырлап та күрсәтте. Шәп җырлар! Каян чыга шушы кечкенә ападан шундый тылсымлы моңнар?!. Мин аңа озак кына сокланып карап тордым. Ничек соң әле ул бу күркәм җырларны миңа бирергә җөрьәт иткән, миңа — гади студент малайга?! Нәрсә тапкан ул миндә? Бу сорауга мин беркайчан да җавап таба алмадым.

Сара апа гомере буе матур җырлар язды. Алар барысы да тирән эчтәлекле, күңелгә тиз уелып, мәңге җанга сеңә торган булдылар. Сара апа халыкка нинди җыр кирәген белеп язды. Ә менә үзенә багышланган бер җыр да юк. Шигырен генә булса да языйм әле.

Безнең өчен бик күп җырлар
Язгансың син, Сарапа!
Ә үзеңә бер җыр язган
Кеше юк бит, чынлапта.

"Сагынмагыз!" — дигән идең,
Сагынабыз, Сарапа.
Чөнки язган җырларын
Барыбыз да ярата.

Ничек кенә яратабыз,
Эх, белмисең, Сарапа!
Үзебез дә гел җырлыйбыз,
Җырлатабыз сорап та.

Алмаз ХӘМЗИН



Илдар ӘХМӘДИЕВ, «Чаян» № 11, 1962



Иван ХАНТИМЕРОВ, «Чаян» № 16, 1977

БЕР ФИКЕРГӘ — ИКЕ КАРАШ

Рашат Низами: СССРдан менә дигән ил килеп чыгар иде, әгәр сәяси маразм чәчәк атмаган булса...

Алмаз Хәмзин: Ә менә хәзер РСФСРында шул маразмның җимеше белән тукланабыз.

Р. Н.: Джордж Бушка Гыйрак нефте кирәк иде, ә Эрдоганны Сириядәгесе кызыктыра.

А. Х.: Ә мине үзебезнеке кызыктыра да бит... акчам юк, хаким түгелмен...

Р. Н.: Алмаз туган, синең белән миндә Җирнең тарту көчен җиңәрлек көч бар микән?

А. Х.: Барын бар, ләкин нефтен суырып чыгарып сату егәре юк.

Р. Н.: Язучы каләме тукран томшыгына тиң: ул һаман саен җан тырмашып хакыйкатькә юл яра.

А. Х.: Халыкта “Тукран тәүбәсе” дигән әйтем бар, минемчә, бу хәзерге язучыларга, ягъни безгә бик туры килә.

Р. Н.: Кеше үзенең йөрәге шикелле тәүлек буе эшләсә, атна ахырында аяктан егылыр иде!

А. Х.: Кеше ялкау бит ул, шуңа күрә үзеннән-үзе эшләп утыручы йөрәк куелган да инде аңа.

Р. Н.: Сүзнең муены нечкә — кайсы якка каерасың, шул якка таба борыла.

А.Х.: Шулай шул — сүз генә түгел, Рашат дус, үзең дә боргаланасың үзеңә кирәккәндә...

БАЛАЛАР БАКЧАСЫНДА

...Апалары әкият укый:
Куркыныч соң ахыры...
– Их, малайлар, бераз тартып
Керми булмас, ахры...

ЗУР ЙОМЫШ

Депутатның эше бик күп:
Моны тик үзе белә.
Халык янына йөри ул
Зур йомыш белән генә.

ЯЗ ШАУКЫМЫ

...Яз җитүгә «мәхәббәт» дип
Сулкылдый иде йөрәк...
Хәзер башта (их, егетләр!) –
Сәнәк, тырма һәм көрәк...

Ринат АБЗАЛОВ



Александр АЛЁШИН



Александр КОСМЫЛИН



Виктор БОГОРАД



ЧуАр пресса

ГОГОЛЬ ЯЛ ИТӘ!

Украина президенты сайтында электрон петицияләр бүлегендә гадәти булмаган һәм хәтта акылга сыймаслык тәкъдимнәр бар. Мәсәлән, илнең кайбер гражданнары Днепрны Азов диңгезенә борырга һәм Таганрог шәһәрен су астында калдырырга, канал казырга һәм Кырымны утрауга әйләндерергә, Россиянең спутниклары узган өчен түләү алырга, ришвәт алуны законлаштырырга, илнең бөтен җитәкчеләрен Украина флагы төсендәге костюмнарга киендерергә, үзләре авызга очып керә торган галушкалар ясарга тәкъдим иткәннәр. Кыскасы, мондый уйдырмалар хәтта Гогольнең башына да килә алмагандыр.

ШОКОЛАДЛЫ ТУҢДЫРМА

Чаллының "Славица" фабрикасына яңа сорт туңдырмаларын ясаудан туктарга мәҗбүр булалар. Шоколад белән капланган "Обамка" дигән оригиналь исемле туңдырма диңгезнең аръягында яшәүчеләрнең күңеленә хуш килмәгән. Күп кенә Америка басмалары фабриканы антиамериканизмда, дискриминациядә һәм расизмда гаепләгәннәр. Моңа җавап итеп "Обамка" ясаучылар бу партия туңдырманың сынау өчен ясалган булганын хәбәр иткәннәр. Туңдырманың тәмен татып карарга да өлгермәгәннәр.

ТӨЗӘТЕП БУЛМЫЙ

"Такси" фильмы буенча билгеле француз актеры Сами Насери тормышта да тизлекне бик ярата. Моның өчен аны күп тапкырлар машина йөртү таныклыгыннан мәхрүм иткәннәр. Шушы көннәрдә Самины кулга алганнар һәм полиция участогына алып килгәннәр. Аның тагын таныклыгын алганнар. Бу юлы таныклык Украинаныкы булып чыга.

Виталий ФЕОКТИСТОВ





ШАЯРТМЫЙБЫЗ-КӨЛМИБЕЗ

ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!

Хәбәр итәбез: икенче яртыеллыктан башлап «Чаян» ике тапкыр калынрак булып чыга башлаячак. Ике санны бергә кушып, журналны айга бер тапкыр чыгарырга карар кылынды. Айлык «Чаян» элеккечә сезнең тугры шаян дустыгыз булып калыр дип өметләнәбез!

Яңартылган «Чаян»ны катлаулыкларсыз алыр өчен язылу тәртибендәге үзгәрешләргә игътибар итегез.

Татарстан укучылары аны «Почта России» каталогы, шулай ук онлайн https://podpiska.pochta.ru аша эшли алалар.

Бу очракта язылу индекслары татарча журналга П2438, ә русчасына П2440 булачак.

ОАО «Агентство «Роспечать» каталогында язылу индекслары элеккечә калды: 73488 – татар телендә, 73489 – рус телендә. Алар буенча Россия һәм Татарстан укучылары языла ала.

«Чаян» өегезгә кояш булып балкып керсен!



Чит ил басмаларыннан шаян рәсемнәр



Бәһрам РАУХАНИ (Иран)



Мирослав БАРТАК (Чехия)



БИЗАРРО (Италия)



Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Багучы — клиентка:

— Мин сезнең киләчәгегезне күрәм. Ул искиткеч матур: югары дәрәҗә, сез баскыч буйлап һаман саен югарыга үрмәлисез, сез күркәм сыйфатта.

Клиент:

— Мин боларны үзем дә беләм, чөнки мин пожарный.

• • •

Хатыны руль артында иренә кычкыра:

— Минем тормозларым эшләми!

— Кыйммәтле булмаган берәр нәрсәгә бәрелергә тырыш!

• • •

— Әнием, яңа төзелгән балалар шәһәрчегендә уйнарга ярыймы?

— Юк, улым, өлгерә алмассың. Мэр карагач, аны башка ишегалдына күчереп куячаклар.

• • •

Гаҗәеп хәл: сорап китәсем булса, эшең шулхәтле кирәкле һәм җитди, диләр. Әгәр дә инде хезмәт хакын арттыру турында сүз кузгатсам, эшемнең әллә ни әһәмияте дә юк икән.

• • •

Начальник сәркатибенә:

— Сез якшәмбе көнне нишлисез?

Сәркатиб кыз, очрашырга чакыра дип уйлап:

— Бернинди эшем юк.

— Менә нәрсә... Бүген якшәмбе түгел!

• • •

Эчүчелеккә каршы көрәш темасына киңәшмәдә – директор цех начальнигына:

— Кулланылган чаралар турында сөйләгез.

— Барлык күрсәтмәләрегез дә үтәлде.

— Нindиләре?

— Ни, бит, һәркемнең үзенеке.

• • •

Ике пенсионер каршыннан кыз үтеп бара.

— Их, булса иде миңа хәзер 20 яшь.

— Акылдан шаштың мәллә? Биш минутлык рәхәтлек өчен соңыннан 40 ел эшләргәме?



ЧАЯН (СКОРПИОН)
САТИРА һәм ЮМОР ЖУРНАЛЫ
№ 1 2016

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры һәм баш редактор
Рафаэль ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш редактор урынбасары: Ринат АБЗАЛОВ
Баш редактор урынбасары, баш рәссам: Александр АЛЁШИН
Үсеш бүлеге: Әдилә БАҺАВЕТДИНОВА
Марс САБИРОВ
Җаваплы секретарь: Гөлнара ЗАМАЛДЫНОВА
Бүлек редакторлары: Людмила САФИУЛЛИНА
Артём СУББОТКИН
Алмаз ХӘМЗИН
Лилия ӘХМӘТОВА
Гүзәл СӘНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Ләйсән ФӘЛӘХОВА

УЧРЕДИТЕЛЕ: «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итүче Федераль служба (Роскомнадзор) идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты: Эл № ФС77-61789, 18 май, 2015 ел.
Нәшер итүче: АО «ТАТМЕДИА»
Адрес: 420047 Казан, Академическая ур., 2
Редакция фикере авторлар фикере белән тәңгәл килергә мөмкин.
Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.
Реклама белдерүләренең дөреслеге өчен реклама бирүче җаваплы.
Басма 16 яшьтән өлкәнрәк укучылар өчен чыгарыла.
«Чаян»нан икенен күрсәтмичә журнал әсәрләрен файдалану тыела.



татмедиа
Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00,
тел./факс: 222-05-54.
16+
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan.su
Редакциянең адресы: Декабристлар ур., 2, ТР, Казан, 420066

Айдар ХӘМЗИН

БЕЗНЕҢ РӨСТӘМ

“Чаян”ның “Авылым мәзәкләре” сәхифәсендә, даими рәвештә диярлек, Ташлык авылының гади кешеләре турында шактый кызык хәлләр, хатирәләр басылып килде. Ләкин башка төбәкләрдән шундыйрак материаллар, ягъни “Чаян”ча язылган темалар журналда, нигәдер, бик аз чагыла. Язмыйлармы, кыенсыналармы, әллә бүтән авыллар күңелсез яшиләрме? Бөтен Татар дөньясында Түбән Кама районындагы Ташлык авылы гына шундый күтәренке рухта гомер итеп ятмыйдыр бит?!

Менә тагын шул авылның бер гади кешесе – Бөтендөнья Татарлар конгрессының Түбән Кама бүлекчәсе җитәкчесе, “Шинник” спорткомплексы директоры Мәҗит улы Рөстәм Ганиев турында авылдашы Айдар Хәмзинның кызыклы хатирәләре.

Рөстәм Ганиев Ташлык авылына 1994 елда килеп чыга, авылыбызны ошатып, шушында төпләнергә ниятли. Расим атавы дигән урынга шул ук елны, үзе әйтмешли, беренче кадагын кага. Мин ул елларда җирле үзидарә рәисе булып эшли идем. Рөстәм абыйның ул вакытта әйткән сүзләре истә калды:

– Айдар, авылга кулымнан килгән кадәр булышырмын, әгәр дә кайвакыт минем тарафтан Ташлык авылы өчен ят булган яки дөрес булмаган гамәлләр эшләнгән икән, оялып торма, йөземә бәреп әйт, төзәтербез, – диде. Рөстәм абый сүзендә торучы сирәк кешеләрнең берсе булып чыкты. Аның башлангычы һәм ярдәме белән авылыбызга газ керде, буа ясалды, библиотека, мәчет, Мәдәният йорты төзелде. Балалар бакчасы төзелеше белән янып-көеп йөрде һәм ул бүгенге көндә инде сафка да басты.

МИН – АТАУДАН

Әле күптән түгел генә Ташлык авылында урамнар концерты булды. Югары оч, Арьяк, Яңа урам һәм Түбән оч урамнары дүрт көн буе Мәдәният йортында чыгыш ясадылар. Халык шулкадәр күп, алма төшәрлек урын да юк, урын алып калу өчен кайберәүләр сәгать дүрттән чыга башладылар. Соңгы концертны Түбән очлар куйды. Тамаша тәмам булганнан соң, сәхнәгә Рөстәм абый күтәрелде һәм рәхмәт сүзләреннән соң, авыл көенә бер куплет җыр башкарды. Халык аның бу чыгышын алкышлап кабул итте, кемдер тамаша залыннан:

– Рөстәм, син кайсы урам өчен чыгыш ясыйсың, – дип кычкырып сорап куйды.

– Мин Атаудан, Атау өчен чыгыш ясыйм, – дип куйды Рөстәм абый.

Бөтен Ташлык халкы атауның Югары оч белән Арьяк арасына урнашканын, ә адресы буенча Киров урамына керүен белә. Менә шушындый концертлар вакытында Атауны бар урамнар да үзләренә кертергә теләп тарткалаша торган иделәр.

МИНЕМ ТАНЫШ МАЗ МАШИНАМ БАР

Ташлык Сабан туена әзерләнәбез. Килгән иганәчеләр белән Сабантуйның бюджетын ачыклыйбыз. Килмәгәннәренә Рөстәм абый үзе шалтыратып, кемнең күпме ярдәм итә алачагын белешә, җавап бирмәгәннәрен тәнкыйтьләп ала, кайберләренә тавышын күтәреп:

– Менә мин бирдем, Мартынов, Әнәс Әхәтович бирде, ә син нишләп бирмисең, – дип ачуланып та ала. Хәллерәк иганәчеләр беткәч, авыл кешеләренә күчәбез, аларны кемнәр әйләнеп чыгачагын билгелибез.

Рөстәм абый шул вакыт, нәрсәдер исенә төшереп, телефоннан кем беләндер югары тонда сөйләшеп алды да:

– Базарда берәү һаман бурычын кайтара алмый, Сабантуйга әйберләтә бирергә ризалашты, Камил Әхәтович (комиссия рәисе) иртәгә машинаңны җибәр, алып кайтырга кирәк ул товарларны, барыбер түли алмас, карале машинаның зуррагын җибәр, күбрәк алып кайтырсыз, – диде.

Мин бу хәбәргә бик шатланып:

– Рөстәм абый, минем таныш шоферым бар, аның МАЗ машинасының әрҗәсе шулкадәр зур, бөтен Сабантуйга җитәрлек товар алып кайтырга була, – дидем.

– Син дә абыең шикелле шаян, – дип куйды Сабантуйның төп иганәчесе, абыем Алмаз Хәмзингә ишарәләп.

ТУЗГА ЯЗЫЛГАН СҮЗЛӘР

Рөстәм абый минем туган көнгә Бәкер санаториесендә ял иткән җиреннән кайтты. Житмәсә, апасының юбилее да шушы көнне үк икән. Аның юбилейда әйткән мәгънәле сүзләре истә калды:

– Айдар, татар халкының тузга язмаган сүзләрне сөйләп йөрмә дигән мәкале бар, мин сиңа Себердән махсус кайтартылган каен тузына язылган Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының Түбән Кама муниципаль районы җирле оешмасы исеменнән Сезгә, халкыбызның тарихын, моңын, телен, мәдәниятен саклап калуда куйган хезмәтләрегез өчен Рәхмәт хатын тапшырам.

Затлы бүләкне кабул итеп алганда, мин җавап сүзе белән түбәндәгеләрне әйттем:


– Хөрмәтле Рөстәм абый, мактау сүзләрегез, теләкләрегез өчен зур рәхмәт, сезнең тузга язылган рәхмәт хаты өчен, җавап йөзеннән Ташлык авылының “тузга язмаган” мәзәкләре язылган китабымның компьютерда үзем чыгарган беренче нөсхәсен бүләк итәм, – дидем.

Уйна да, уйла да!

ЧАЯНВОРД

КОМПОЗИТОР ... ӘХМӘДИЕВ
КОМПОЗИТОР ФАСИЛ ...
ХАЛЫК РӘССАМЫ ... ЯКУПОВ
ЧЫНГЫЗ ...
ИТАЛИЯДӘГЕ ТУРИСТИК ТӨБӘК
ЧӘЧ БУЯВЫ (-1)
МОРЗА ТИТУЛЫ
АРТИСТ, РЕЖИССЕР ... ХӘМЗИН
ДИНГЕЗ КЫСЛАСЫ
ЯСАЛМА ОРГАНИЗМ (АББР.)
ҺӨҖҮМ
ЯЗУЧЫ ... ЕНИКИ
ЯҢГЫР
АРТИСТКА ... ГӘРӘЕВА
ДИРИЖЕР ... ХАНАТУРЯН
ГАДИ, ЖИҢЕЛ
САУ, СӘЛАМӘТ
ФУТБОЛ УЕНЫНЫҢ МАКСАТЫ
НОТА
ЖЫРЧЫ ... ШАҺБАН
БЕЛӘН КӘЖӘ (ТУКАЙ) ҺӘМ
(-1)СТЕНА ЛАМПАСЫ
КОМПОЗИТОР ... ХӘСӘЕНОВ
КОНДИТЕР ФАБРИКАСЫ
ТРАГЕДИЯСЕ (ТАКТАШ)
ИКМӘК
"... ЧУКЛАР ДИМ-ДИМ, НИК ЖИЛФЕРДИ ЖИЛ ДӘ ЮК"
"СУТЫЙ"
(-3) БИЮ КӨЕ
БРАВО!
"АКТАНЫШ ... ЛАРЫ"
ӨСТӘЛ УЕНЫ
"ЧЫГАСЫҢ ДА ИДЕЛ ... ЛАРЫНА..."
ШАГЫЙРЬ ... РӘХМӘТ
РОССИЯДӘ КИНО ПРЕМИЯСЕ
КЫЛЛЫ МУЗЫКА ИНСТРУМЕНТЫ
...(-1)-БЕЛЕМ
ОСТАСЫ
ПАСПОРТТА ИНИЦИАЛЛАР БИЛГЕСЕ
ШАГЫЙРЬ ДЕМЬЯН ...
ЖЫРЧЫ ... БАСЫЙРОВА
исеме
исеме
исеме

Ринат АБЗАЛОВ төзеде.



1. Урысның “ни пуха, ни пера” дигән әйтеме нәрсәне күз алдына китерә?

2. Ни өчен Обама үзеннән үзе көлми?

3. Яба һәм жибәрми. Нәрсә ул?

4. Кондуктор кем ул?

5. “Законлагы карак” нәрсәне аңлата?

6. Тешләрне иң яхшы саклый торган нәрсә?

7. Нәрсә ул тулы наркоз?

ЖАВАПЛАР

1. Раскладушканы. 2. Расист булып күренмәс өчен. 3. Юрган. 4. Мазай бабай кирәсенчә. 5. Дәүләт өчен законнар уйлап чыгарырга утыртылган карак. 6. Кеше эшенә кысылмау. 7. Авыру кешегә операция ясаганда хирурглар бригадасының йокыга китүе.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда ике жыр исемен укыгыз. Журналыбызның 8 нче санында басылган чаянвордның тикшерү сүзләре – **«ШОМЫРТ ЧӘЧӘКЛӘРЕ АК КЫНА», «УЕЛ».**


Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Р. ЗАҺРИЕВ (Кукмара р-ны, Югары Арбаш ав.),
Р. ИШМӨРАТОВ (Арча р-ны, Урта Сәрдә ав.),
М. МИҢНЕМУЛЛИНА (Балтач р-ны, Норма ав.),
М. МӨХӘММӘДЬЯРОВА (Яшел Үзән р-ны, Яке ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).

Җиңүчебез – Яке авылыннан **Мәүлия МӨХӘММӘДЬЯРОВА!**

КАРИКАТУРА ОСТАЛАРЫ

Владимир НЕНАШЕВ (Россия)



Владимир НЕНАШЕВ – Россия карикатурасының танылган остасы. Ул Выборг шәһәрендә яши һәм эшли. Владимир карикатурачы гына түгел, ә журналист һәм дизайнер да. Ә безнең укучыларыбыз аны күбрәк шаян рәсемнәре буенча белә.



